**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2021елның 27 гыйнвары 86 номер

# КАРАР

## Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычлар булу (булмау) турында салым түләүчеләргә мәгълүмат бирү буенча эшләрне оештыру турында

Татарстан Республикасы Федераль салым хезмәте идарәсе һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Башкарма комитетының мәгълүмати хезмәттәшлек итүе буенча 2021елның 22 гыйнварындагы 2.1-21/13номерлы Килешүен гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының структур бүлекчәләренә салым түләүчеләргә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычлары барлыгы (булмау) турында мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм эшкуарлык бүлегенә 2021 елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 07 августындагы 674 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелгәндә һәм дәүләт вазыйфаларын башкарганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек Тәртибе нигезендә, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруга гариза җибәрергә.

3. . Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo/tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.В. Бламыковка йөкләргә.

Җитәкче А.А. Новиков